ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** с. Тюлячи **КАРАР**

**«** 18 **»** гыйнвар 2018 № 19

Ф. Туишев исемендәге район гармунчылар конкурсы буенча нигезләмәне раслау хакында

«Теләче муниципаль районы Район мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениясе директоры вазифаларын башкаручысының 10.01.2018 нче елгы 4-нче номерлы хаты нигезендэ, 6 октябрь 2003 елның 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә жирле узидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законы нигезендә,

Карар бирәм:

1. Ф. Туишев исемендәге район гармунчылар конкурсы турындагы нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.
2. Элеге карарның утәлешен тикшеруне район Башкарма комитеты житәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.В. Галеевка йокләргә.

Җитәкче Р.Р. Нуруллин

Теләче муниципаль
районы Башкарма
комитетының
карарына кушымта

**Ф.Туишев исемендәге гармунчыларның**
**1 район смотр –конкурсына Нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмә

1.1. Ф. Туишев исемендәге гармунчыларның I район смотр-конкурсы (алга таба — Конкурс), инструменталь традицияләрен пропагандалауга һәм үстерүгә, аларны саклап калу, талантлы башкаручыларны ачыклау һәм аларга ярдәм итү, иҗади яшьләрдә кызыксыну уятуга юнәлтелгән.
1.2.Чара ике елга бер тапкыр үткәрелә.
1.3. Нигезләмәнең юнәлеше:
- конкурсның максат һәм бурычлары;
- конкурста катнашу өчен башкаручыларны сайлап алу тәртибе;
- конкурсны оештыру һәм уздыру тәртибе.
1.4.Конкурс Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге, Теләче муниципаль районы мәдәният Йорты тарафыннан оештырыла.

## 2. Конкурсның максаты һәм бурычлары

2.1.Конкурсның максаты – ансамбльләрне, солистларны ачыклау, аларның иҗатын популярлаштыру, халык инструментариясенең хәзерге торышы һәм үсеш перспективаларын билгеләү.
2.2.Конкурсның бурычлары –башкару осталыгын арттыру һәм активлаштыру, коллективларларның һәм аерым башкаручыларның иҗат эшчәнлегендә,репертуарны баетуда ярдәм итү, җәмәгать игътибарын инструменталь музыкага җәлеп итү һәм яшьләрне патриотик тәрбияләү.

## 3. Конкурсны гамәлгә куючылар һәм оештыручылар

3.1. Конкурсны гамәлгә куючы Теләче муниципаль район Башкарма комитеты.
3.2. Оештыру, үткәрү һәм нәтиҗәләр ясау өчен конкурсны оештыру комитеты төзелә (алга таба – Оештыру комитеты ).

## 4. Конкурста катнашучылар

4.1.Конкурста Теләче муниципаль районының гамәлдәге авыл мәдәният йортлары,авыл клублары, район мәдәният Йорты,балалар сәнгать мәктәбе каршындагы укыту коллективлары һәм солистлары, шулай ук бәйсез рәвештәге башкаручылар катнаша ала .

4.2. Конкурс әсәрләрне гармунда, тальянда, баянда, аккордеонда башкаруны күздә тота.
4.3. Катнашучыларның яше – 9 яшьтән һәм аннан өлкәнрәк.

## 5. Конкурсның номинацияләре һәм категорияләре

5.1.Конкурс 3 номинациядә үтә:
-солистлар;
- кече ансамбльләр (2кешедән алып 4 кешегә кадәр);
- гаилә ансамбльләре.
5.2. Номинацияләр яше буенча өч категориягә бүленә :
- балалар (17 яшькәчә);
- яшьләр (18 яшьтән-35 яшькәчә);
- өлкәннәр (36 һәм аннан да өлкәнрәк яшьтә).
Ансамбльләрнең яшь категориясе 75% /25% нисбәттән чыгып исәпләнә.

## 6. Конкурсантларга таләпләр

6.1. Катнашучылар бәйгегә өч төрле характердагы әсәр тәкъдим итә, бер номерның озынлыгы 3- минуттан да артык булырга тиеш тугел.
6.2. Конкурс программасы коллективның яки аерым башкаручының тематик һәм жанр юнәлешен, аның иҗатын, башкару мөмкинлекләрен, осталыгын, әлеге стильне күрсәтергә тиеш.
6.3. Конкурста башкару очен тәкъдим ителә:
- халык музыкасын эшкәртү, аранжировка;
- оригиналь әсәрләрнең кече формаларын;
- такмакларны инструменталь уен коралы белән баету;

## 7. Жюринең бәяләү критерийлары

7.1. Репертуарның узенчәлекле, оригинальлеге һәм төрле жанрда булуы.
7.2. Башкару осталыгы (техника, импровизацияне, материалны яхшы белү, ансамбльдә уенга кушылу).
7.3. Нәфис тәэсир (сәнгатъчән образ тудыру, артистизм).
7.4. Сәхнә киеме

## 8. Жюри

8.1. Конкурска жюри (алга таба − жюри) музыкаль жанр өлкәсендәге белгечләр, халык уен кораллары укытучылары арасыннан формалаша. Жюри үз эшен зона турыннан алып йомгаклау турына кадәр башкара. Жюри, зона турларында составында кимендә өч кешедән торган жюри рәисе һәм жюри әгъзалары белән эшли ала.
8.2. Конкурсның жюри составы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге боерыгы белән раслана.
8.3. Жюри катнашучыларның чыгышларын 10 балл системасы буенча бәяли (0-10), беркетмә нигезендә рейтинг буенча иң югары балл җыйган катнашучы җиңүче дип исәпләнә.

## 9. Бәйгене оештыруның шартлары һәм тәртибе

9.1. I этап – район зонасы (2018 елның гыйнвар-февраль айларында) туры түбәндәге мәдәният йортларында уза:
-Иске Җөри мәдәният йортында – 25 гыйнварь;
- Олы Кибәхуҗа мәдәният йортында – 6 февраль. 1 этапта җиңүчеләр Теләче муниципаль районы данын республика зона турында яклау хокукына ия булалар.
9.2. II этап – республика зона туры, 2018 елның 17 февралендә Теләче муниципаль районының район мәдәният Йортында уза.
9.3. Жюри әгъзаларының карары күпчелек тавыш белән кабул ителә һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә.
9.4. Жюри карары буенча тиешле номинация һәм категорияләр буенча I, II, III дәрәҗә Лауреат исеме бирелә.

## 10. Бәйгедә җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы

10.1. Барлык катнашучылар (коллективлар) район туры конкурсында дипломнар, ә җиңүчеләр I, II, III дәрәҗә Лауреат дипломнар белән бүләкләнә.
10.2. Жюри хокуклы:
- барлык исемнәрне бирмәскә;
- мактаулы исемне катнашучылар арасында буләргә;
- номинация эчендәге категорияләргә төзәтмәләр кертергә .
10.3. Жюринең карары төгәл һәм шикаятьләр кабул ителми.

Ф.Туишев исемендәге
гармунчыларның I район
смотр-конкурсын
үткәрү турында нигезләмәгә
№ 1 кушымта

Ф.Туишева исемендәге гармунчыларның I район смотр-конкурсын оештыру комитеты составы

Жюри рәисе:

| | | |
|---|---|---|
| Гасыймов Ф. М. | - | Теләче муниципаль районының балалар сәнгатьмәктәбе халык уен кораллары оркестры җитәкчесе. |
| Жюри әгъзалары: | | |
| Минһаҗев Р. И | - | Теләче район мәдәният йортының культорганизаторы; |
| Шайдуллин И. В | - | Субаш авыл клубы аккомпаниаторы; |
| Сафиуллин И. И | - | балалар сәнгать мәктәбенең музыка укытучысы; |
| Заббаров А. Ф. | - | Баландыш төп белем бирү мәктәбенең музыка укытучысы. |